КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 гыйнвар г.Казань № 42

Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында

Тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәлә) расларга:

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә Татарстан Республикасында орлыкчылыкны үстерүне яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар буенча чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән әче туфракларга известь кертү чараларын гамәлгә ашыру тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә мелиорация эшләре үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Җәнлек үрчетү хуҗалыкларына читлектәге кыйммәтле мех бирә торган җәнлекләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Мелиорация объектларын яңадан техник җиһазландыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең аграр юнәлештәге квалификацияле белгечләр әзерләүгә бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы әзерләү-куллану кооперативларының, әзерләү оешмалары һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренең ит, йон һәм күн чималын сатып алу, эшкәртү һәм сату чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендәге кечкенә фермалар төзүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга башмак таналар һәм тана сыерларның товарлы һәм нәселле баш исәбен сатып алуга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга яшь кошлар (каз, үрдәк, күркә, бройлер чебиләр) сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга өч яшьтән зур булган бияләрне карап тоту өчен азык сатып алуга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сыерларга кирәк-ярак җиткерү буенча ветеринария профилактикасы чараларын үткәрүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына оешмалар мөлкәтенә салым түләү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә, кулланучылар җәмгыятьләренә, агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ягулык-майлау материалларына чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Кулланучылар кооперацияләре оешмаларына күчмә сәүдәне гамәлгә ашыру өчен махсус автотранспорт сатып алу белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Агросәнәгать комплексы өлкәсендә фәнни тикшеренүләргә һәм эшләргә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан грантлар бирү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына

Тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында законында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына әлеге максатларга каралган акча исәбеннән конкурс нигезендә агросәнәгать комплексы өлкәсендә фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр алып бара торган милекнең барлык төрендәге оешмаларга бирелә торган грантларның гамәлгә куючысы булырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин